# Аннотация к рабочей программе воспитателей по обучению татарскому языку

―Татарстан Республикасы халыклары телләре турында‖ Татарстан Республикасы Законында һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасында мәктәпкәчә милли белем бирү өчен кирәкле шартлар булдыру каралган.

―Балалар бакчасында рус балаларын татарча аралашырга өйрәтү программасы (алга таба программа) алда күрсәтелгән чыганакларга нигезләнеп төзелде.

Программа 4 яшьтән 7 яшькә кадәр булган рус телле балаларның татарча аралашырга өйрәтү эшчәнлекләрен үз эченә ала. Программа мәктәпкәчә яшьтәге баланың үсеш закончалыкларына, шәхси һәм эшлекле якын килү турындагы фундаменталь тикшеренүләргә, тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология принципларына, сөйләм барлыкка килү концепциясенә (Л. С. Выготский, В. В. Давыдов, Е. И. Пассов, П. Я. Гальперин), гамәли эшкәртмәләр һәм методик киңәшләргә, мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген ачыклаучы норматив хокукый актлар, нигезләмәләренә көйләнгән.

**Программаның максаты һәм бурычлары.**

―Балалар бакчасында рус балаларына татар теле өйрәтү‖ программасына нигезләнеп ―Татарча сөйләшәбез‖ укыту-методик комплекты 4 яшьтән 7 яшькә кадәр булган рус телле балаларны 167 сүз кысаларында татарча аралашырга өйрәтүне үз эченә ала. Шуннан чыгып эш программасына түбәндәге максат, бурычлар билгеләнде.

Максат: Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны 167 сүз кысасында информацион–коммуникатив технологияләр кулланып татарча аралашырга өйрәтү.

Бурычлар:

1.Сүз байлыгын арттыру, сөйләм күнекмәләре формалаштыру.

2.Предметларны, аларның билгеләрен һәм хәрәкәтне белдерүче сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.

3.Көндәлек яшәеш ситуацияләреннән чыгып диалоглар төзү.